Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



№2
Октябрь 2017 г.

## Груда книг не заменит учителя




*Дорогие коллеги!*

Я знаю, что вы не зря выбрали свой сложный, трудный, насыщенный взлетами и падениями путь. Не зря потому, что никто другой не сможет так, как вы, научить ребенка, пришедшего к вам с распахнутой душой, верить в счастье, дружбу, верность; воспитать в нем преданность земле, на которой он живет, научить его любить учиться, каждое мгновенье открывать для себя что -то новое из необъятной вселенной знаний. Вы знаете, как помочь маленькому человеку научиться отстаивать свое «Я» и свой взгляд на мир, брать препят- ствия, которые будут встречаться на его пу- ти. Спасибо вам за ва- ше терпение и муд- рость. И за уроки, ко- торые вы даете. С праздником вас, дорогие мои, – с Днем учителя!

*С уважением,*
*Гульназ Гиниатуллина!*

## Интересно знать!

- **Мальчики из Древней Спарты** несколько месяцев проживали в школе.
- Петр Первый создал **первую школу в России,** где обучались лишь мальчики.
- **Встречи выпускников** возникли в Германии.
- Самым длинным уроком считается тот, который **длился 54 часа.**
- Американские ученики, которые в первый раз попали в школу, **отдают клятву верности своей стране.**

## Как отдыхают спортсмены?

***Лагерь «Ялта-Зай» знаменит своим гостеприимством и хорошими вожатыми. Здесь есть все: футбольное и баскетбольное поле, лыжи-роллерные трассы разных длин. В этот лагерь приезжают дети не только из Татарстана, но и со всей России.***

Распорядок дня там такой:

В 7:05 мы выходим на зарядку. Обычно это пробежка 1500 метров, но бывают исключения и мы выходим на лыжи-роллерах. В 8:00 завтрак. Первая тренировка начинается в 10 часов. Иногда делаем имитацию, бегаем трёх часовой кросс или же делаем объемную работу. Объемная работа бывает как беговая, так и лыжи-роллерная. В беговой объемной работе мы бегаем 30 км, а лыжи-роллерная объемная работа достигает до 60 км.

В 13:00 обед. С 14:00 до 16:00 длится тихий час. Вторая тренировка начинается в 16:30. Обычно играем волейбол или футбол. В силовую работу входит: работа с камнями, резиной. В 7 вечера у нас ужин. После у нас есть 3 часа свободного времени. В это время мы смотрим кино, играем в настольные игры.

В 22:00 отбой. И так повторяется каждый день. За все лето успеваем побывать 3-4 таких лагерях.

Кто-то говорит что лыжный спорт- это самый легкий спорт. Но это не так. Если побывать на месте спортсменов хоть неделю, то ты сразу поймешь какой на самом деле этот вид спорта. Ведь не зря говорят «Не суди по виду, а суди по внутреннему миру».

*Ильназ Дияров,*
*8Б класс*

## В этом выпуске:

«Артек»ка юллама бүләккә! 2
2
Күңел җылысын өләштеләр 3
«...Мин үлмәдем. Исән калдым!” 3
Лента новостей 4
Акция «Энергия Добра» 4
День посадки деревьев 4

# «Артек»ка юллама - бүләккә!

***Һәркем кечкенәдән бирле Артек лагерендә ял итү турында хыяллана, тик күпләрнең бу хыялы чынга гына ашмый. Ә миңа бу бәхет елмайды. Ничек булганын беләсегез килсә, тыңлагыз!***

Быелгы җәем "Алтын каләм" республика балалар, үсмерләр һәм яшьләр фестивалендә катнашу белән башланып китте. Әлеге бәйгедә мин "Басма матбугат" номинациясендә җиңдем. Ярыштан кайтуга ук, безне Арча укучылар сараена Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары Лариса Олеговна Сулима белән очрашуга чакырдылар. Ул "Нур" телерадиостудиясенең эшенә, уңышларына сокланып, безгә "Артек" III Халыкара яшүсмерләр медиафорумының сайлап алу этабында катнашырга тәкъдим итте.

Мин үземнең эшләремне чараны оештыру комитетына юлладым. Күп тә үтми, электрон почтама Мәскәүдән хат юлладылар. Анда: "Рүзәл, без синең мәкаләләреңә югары бәя бирдек һәм 18 октябрьдән - 7 ноябрьгә тикле узучы "Артек" III Халыкара яшүсмерләр медиафорумында көтеп калабыз," - диелгән иде. уйлап кына карагыз, 21 көн буе яр буенда ял бит ул!

Медиафорум барышында без кызыклы шәхесләр белән очрашып, әңгәмәләр корып, журналистиканың төрле юнәлешләрендә эшләячәкбез. Мәсәлән, "Острова" газетасы, радио, "Артек - ТВ" каналлары булдырылачак дип көтелә.

Әлеге чара Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырыла. Форумның төп максаты - медиамәдәниятле яшь буын тәрбияләү. Форумга Россиянең төрле төбәкләреннән 11-16 яшьлек 300 яшь журналист чакырылган, шул бәхетлеләр арасында мин, Рүзәл Шәрипов та бар.

*Рүзәл Шәрипов, 8Б сыйныфы*




# Җыр сәнгате укытучылары очрашты

***23 нче октябрь көнне мәктәп республика җыр сәнгате укытучылары өчен тәҗрибә мәйданчыгы булды.***

Кунакларны каршы алу татар халкының кичке уеннарыннан күренешләр белән башланды. Мәктәп буенча экскурсиядә һәм Бөек Ватан сугышы елларын чагылдырган музейда булганнан соң, 1нче сыйныфларның «ДоМиСолька» ансамбле чыгышы белән дәвам итте. Һәрбер чара файдалы һәм кызыклы итеп үткәрелде. Г.Тукай исемендәге педагогия көллиятенең IVкурс студентлары Роза Шайхиева, Илһам Яруллин 5 нче сыйныфларда «Халкым моңы», «Музыкада табигать матурлыгы» темасына дәресләр күрсәтте.Тәҗрибәле укытучылар студентларның чыгышларын уңай бәяләделәр. Булачак укытучылар Г.Тукай исемендәге педагогия көллиятенең музыкаль тәрбия методика секциясе җитәкчесе Флёра Шакированың куйган таләпләрен җиренә җиткереп үтәргә тырышты.



Заманча шартларда укытучыларның һөнәри осталык дәрәҗәсен үстерү һәм камилләштерү максатыннан үткәрелде әлеге чара. Уңай педагогик тәҗрибәне өзлексез өйрәнү аркылы гына тирән һәм күпкырлы һөнәри белемгә ия булырга мөмкин. Әлеге тәҗрибә мәйданчыгында катнашучылар укыту-тәрбия процессында белемне иҗади куллана белүче югары категорияле җыр сәнгате укытучысы Алинә Мөхәммәтгалиева тәҗрибәсен өйрәнеп, дәресләрендә файдаланачакларын белдерделәр.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлнар Гарипова укучыларының дәрестән тыш эшчәнлекне чагылдырган чыгышы аркылы, милли йолаларга, гореф-гадәтләргә мәхәббәт тәрбияләвен күрсәтте.

Эшчәнлеккә түгәрәк өстәл артында нәтиҗә ясаганда, яңа заман шартларына яраклы, сәләтле шәхес тәрбияләү өчен, мәктәптә уңайлы шартлар тудырылганы әйтеп үтелде. Чыннан да, әлеге уку йортының директоры Гөлназ Гыйниатуллина укучыларның уку -белем алуга булган сәләтен ачуга аеруча нык игътибар итә.

Эшлекле һәм файдалы булды әлеге очрашу. Кунакларны озату вакыты килеп җиткәнне сизми дә калдылар. Иң мөһиме – һәркем канәгатьлек хисе белән китте.

**Рәсимә Ибраева**, 2 нче мәктәп

# Күңел җылысын өләштеләр



Картлар йорты, бигрәк моңсу бу ике сүз.
Тәрәзләрдән тышка баккан ничәмә күз…
Бу күзләрдә яшь пәрдәсе, бетмәс сагыш,
Аңлау кыен… язмышмы бу… әллә ялгыш…

*Юныс Миңнемөхәмәтов*

***Дөньяда иң сабыр йөрәкле кешеләр, мөгаен, картлар йортында тәрбияләнүче-ләрдер. Аларның гомерләре өмет белән нидер көтеп, сагышланып үтәдер кебек тоела. Үз балалары, якыннарына артык булган әби-бабайларга, өлкәннәр ун-көнлеге уңаеннан, аз гына булса да шатлык өләшәсе килә.***

Бу көннәрдә шәһәребез мәктәпләрендә, балалар бакчасында тәрбиялә-нүчеләр килеп аларның күңелләрен күтәрәләр.

Алинә Мөхәммәтгалиева, Чулпан Фидаилевна, Динә Ибраһимова җитәкчелегендә безнең мәктәп укучылары да 27 нче сентябрь көнне бирегә килеп бик матур бәйрәм концерты күрсәттеләр. Ак яулыклы әби-апа-ларыбыз, түбәтәйле аксакалларыбыз хөрмәтенә оештырылган кичә күңелләренә хуш килгәнлеге йөзләреннән күренеп тора иде.

Кемнеңдер үз баласын, йөрәк маен уйлап, кемне-ндер яшьлеген сагынып күзләреннән яшьләр тамды бу минутларда. Яшьле күз-ләрен сөртеп, елмаеп кул чабып утырулары катнашучыларның күңелләрен дәртләндерде дә, моңсуландырды да. Балаларыннан ала алмаган күңел җылысын өләштеләр укучылар ул көнне. Үзләре дә, кызганып, яшь аралаш елмаеп хушлаштылар.

*Алинә Мөхәммәтгалиева*

# «...Мин үлмәдем! Исән калдым!»

***Моңа кадәр, картлар йорты диюгә, күңелне өшетерлек шыксыз бина, моңсу, бетмәс сагыш белән тулы карашларын тәрәзәгә төбәгән әби-бабайлар килеп баса иде. Тик Арчаның өлкәннәр һәм инвалидлар йортына баргач, интернатка булган карашым да, фикерләрем дә үзгәрде.***

Әлбәттә, монда яшәүчеләрнең һәрберсенең язмышы гыйбрәтле һәм берсе дә бирегә рәхәт тормыштан туеп килмәгән. Интернатта яшәүчеләрнең күпчелеге тормышларыннан канәгать. Андыйлар: «Япа-ялгызыбыз, кеше белән аралашырга тилмереп яшәгәнче, гомеребезнең соңгы көннәрен кадер-хөрмәттә уздырабыз», – дип шөкер итә.

Биредә яшәүче 90 яшьлек Фахирә Зыятдинова да – әнә шундыйлардан. Яшьлеге сугыш елларына туры килеп, иң авыр эшләрдә бил бөккән, аннан соң да гомерен хезмәткә багышлаган ул. «Фахирә апа – безнең йортның нуры, яме. Шаян, игелекле әбиебез ул», – ди интернат директоры Гөлназ Төхвәтуллина, аның турында яратып.

- Сугыш елларында Яшел Үзән районында урман кистем. Минем белән бергә эшләүче иратларның кайсысы авырып, кайсысы асылынып үлде. Мин үлмәдем! Исән калдым! Аллага шөкер! Ә кияүгә чыкмадым, чөнки эштән башканы белмәдем. Сугыш беткәч, фермада сарыклар карадым. Берсен дә үтермәдем бит! 1972 елда йортыбыз янды. Бер нәрсәбез дә калмады. Шуннан соң Арчага чыктым да киттем. Безне монда бик яхшы карыйлар. Урынҗирләребез ялт итеп тора. Тәмле ашаталар, мунча кертәләр. Кайвакыт: «ник үлмим икән инде», – дип тә уйлап куям! Урман кискәндә, салкын суда йөреп, аякларыма зыян килде. Әле шулай да 90 яшькә җиттем бит!

Авылга бик сирәк кайтам. Ямансуламыйм үзе, чөнки бик рәхәт яшим монда, - дип рәхәтләнеп көлә Фахирә апа.

Хәер, картлар йортының ак әбиләре булган кебек, намаз бабайлары да бар. Гөлназ Галәветдиновна да, безне Әнвәр Шәфыйков белән таныштырганда: «Ә менә монысы – йорт бабаебыз», – диде. Бормалы-сырмалы балачагы да, катлаулы авырулары да, олыгайган көнендә япа-ялгыз калуы да аның тормышка, кешеләргә булган мәхәббәтен югалтмаган.

*Зөләйха Зәбирова, 9В сыйныфы*



24 сентября в Арске прошел **Форум Юных Граждан Республики Татарстан.** В нем приняли участие обучающиеся нашей школы Рамзиль Сабиров, Алия Хабирова, Рузаль Шарипов и Чулпан Сабирова.

В Форуме приняла участие заместитель Главы Арского муниципального района Любовь Михайловна Осина. Она поддержала все идеи, которые были приняты в Резолюцию, ответила на все интересующие детей вопросы и пообещала оказать поддержку в реализации новых проектов.

Программа форума была очень насыщенной. Работа велась в трех направлениях с учащимися и педагогами.

В конце мероприятия наградили самых активных делегатов форума. Ученики нашей школы получили памятные подрки за побуду номинации “Фото с СДО”.



# Лента новостей



7 октября - день посадки деревьев. В этой акции приняли участие все школы района, в том числе и наша школа. Учащиеся 10 класса посадили деревья вокруг нашей школы.

Выпускники нашей школы каждый год сажают именные деревья. Эта красивая традиция хранится уже в течении нескольких лет. Будем надеяться, что через несколько лет территория нашей школы разукрасится рябиной, липой, елью и другими полезными деревьями.

***#СДОРТ #***
***МӘРХӘМӘТЛЕ ТАТАРСТАН***

Изгелек ул – беркайчан да,
Тузмый торган хәзинә.
Яхшылык эшлик һәрвакыт,
Ул үзе изге дога.

Изгелек эстафетасы атналыгы уңаеннан мәктәп укучылары ветераннарына шефлык күрсәттеләр. Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераннарының өйләрендә булып, бүләкләр өләштеләр, 4нче октябрь көнне мәктәп укучылары бәйрәм концерты күрсәтте. Әбибабайлар укучыларның аларга карата булган ихтирамына рәхмәт белдерделәр.





***Всероссийская акция «Энергия Добра»***

Обучабщиеся нашей школы приняли активное участие во Всероссийской акции «Энергия добра», которая проходила с 6 по 27 сентября 2017 года по всей России. Цель данной акции - распространение в молодежной среде идей рационального использования энергоресурсов с применением эффективных технологий. Участниками акции были учащиеся с 3 по 11 классы. Ребята собрали лампочки и передали в Дом-интернет для престарелых и инвалидов.


**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Ответственный секретарь*** Рузаль Шарипов
***Редколлегия*** Алия Хабирова
Диана Галимова
Ляйсан Шаяхметова
Адиля Киямова
*Адрес* ул. Мостовая 15
***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2


